«Килешенде»
Район башкарма
комитетының мәгариф идарәсе
житәкчесе
А.Ю. Закиева

«Раслыйм»
Балтач авылара үзәк
китапханә директоры
Р.М.Зарипова

Нәфис сүз осталарының район
бәйгесен уздыру хакында

**нигезләмә**

Балтач авылара үзәк китапханәсе бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 133 ел тулу уңаеннан нәфис сүз осталарының район бәйгесен уздыра.

**Бәйгене уздыру максаты:**

- Районда яшәүче нәфис сүз осталарын барлау;
- Балаларда, яшүсмерләрдә туган җиргә мәхәббәт, тугрылык хисләре тәрбияләү;
- Бәйгедә район җирендә яшәүче төрле буын вәкилләренең катнашуына ирешү;
- Районда яшәүче нәфис сүз осталарының башкару осталыкларын камилләштерү;

**Бәйгене уздыру шартлары:**

- Бәйгедә 6 яшьтән өлкән булган һәркем катнаша ала;
- Бәйгенең икенче турына, үзәк китапханәгә, һәр китапханә бердән артык башкаручы тәкъдим итмәскә тиеш;

Программа:

- Һәрбер чыгыш ясаучы бәйгедә Габдулла Тукай иҗат иткән шигырь сөйләргә тиеш; Икенче әсәр ирекле темага.
- Чыгыш ясаучының вакыты 4-5 минуттан артмаска тиеш;
- Татар, рус телләрендә чыгыш ясарга мөмкин;
- Бәйгедә чыгыш ясаучы һәр кешегә китапханәче анкета тутыра. Анкета. бәйге башланыр алдыннан методистка тапшырыла. Анкетада бәйгегә катнашучы хакында түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш: (Фамилия, исеме, әтисенең исеме, туган елы, ае, числосы, тулы яше, яшәгән урыны, мәктәбе(исеменең дөрес язылышы), сыйныфы, баланы бәйгегә әзерләүче укытучының исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, репертуар)

**Бәйгене үткәрү вакыты:**

1 тур-авылларда январь 2019
2 тур **үзәк китапханәдә 8 февральдә сәг. 9 да**

**Җиңүчеләрне бүләкләү:**

Җиңүчеләрне бүләкләү 3 номинация буенча үткәрелә:
6 яшьтән 14 яшькә кадәр;14 яшьтән 24 яшькә кадәр;24 яшьтән - .....
Һәрбер номинация буенча 3 урын бирелә.